Кукмара муниципаль районы
Березняк авыл җирлеге Советы

КАРАР

30 май , 2025 ел № 17

Березняк авыл җирлеге Советының 2018 елның 01 июнендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Березняк авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Березняк авыл җирлеге Советының 2018 елның 01 июнендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә), Березняк авыл җирлеге Советының 2018 елның 08 октяберендәге 26 номерлы 2020 елның 21 декабрендәге 15 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 39 номерлы, 2024 елның 17 июнендәге 16 номерлы, 2024 елның 16 августындагы 25 номерлы, 2024 елның 03 декабрендәге 35 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Муниципаль берәмлек башлыгына айлык акчалата түләү түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата түләүнең күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | Уникенче төркем (халык саны 1,5 мең кешегә кадәр) |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 21 091,0 |

б) 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Айлык акчалата түләү 12 төркемгә кертелгән муниципаль берәмлек башлыгы өчен нормативтан артмаган күләмдә түләнә – елына 15,48 айлык акчалата түләү.»;

в) 3.1 пунктның беренче абзацында «13990» санын «15389» санына алмаштырырга.

г) 3.5 пунктында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) айлык акчалата түләү – хезмәт окладына карата 58 проценттан артмаган күләмдә.»

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Березняк авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Шәрипов